**СОВЕТ**
**АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“ 24 “ сентябрь 2018 нче ел №49-94

## “ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БИЛӘМӘСЕНДӘ ГРАЖДАННАРНЫҢ ҮЗАРА САЛЫМ АКЧАЛАРЫН КЕРТҮҺӘМ ФАЙДАЛАНУ МӘСЬӘЛӘСЕ БУЕНЧА ҖИРЛЕ РЕФЕРЕНДУМ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА”

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлауга хокукы һәм референдумда катнашуга хокукы турында”гы Федераль законның, 12 нче июнь 2002 нче ел “67-ФЗ, 15 нче матдәсе нигезендә, шулай ук “Россия Федерациясендә үзҗитәкчелекне оештыру турында” Федераль Законның, 6 нчы октябрь 2003 нче ел № 131-ФЗ, 22 нче, 56 нчы матдәсе нигезендә, “Җирле референдум турындагы” Татарстан Республикасы законы 24 нче март 2004 нче ел, № 23-ТРЗ, 17 нче, 18 нче матдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы, “Акъяр авыл җирлеге” Уставының 11 нче матдәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Акъяр авыл җирлеге башкарма комитетының 14.09.2018 нче елның №28 номерлы ”Референдум үткәрүгә башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Акъяр авыл җирлеге Советының 14.09.2018 нче елнын № 48-93 номерлы ”Референдум үткәрүгә башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Акъяр авыл җирлеге Советы

**КАРАР** бирә:

1. Акъяр авыл җирлеге биләмәсендә, үзара салым җыю һәм куллану буенча, 2018 нче елның 18 нче нояберенә референдум көнен билгеләргә.
2. Референдумда каралачак сорауларны барларга:

“Сез , Акъяр авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән, 2019 нчы елга, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары тормыш иптәшләре, 1 нче группа инвалидлар, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләр азат ителә.

Үзара салым түләүдән җыелган акчалар түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- **Акъяр авылы, Яшьләр урамындагы урам юлларын тәртипкә китерүгә ;**
- **җәй һәм кыш айларында авыл эчендәге урамнарны тәртиптә тотуга;**
- **авыл суүткәгечләрен төзекләндерүгә, су белән тәэмин итүчегә түләүгә;**
- **“Челнинка” елгасының элеккеге култыгын чистарту һәм төзекләндерү;**
- **“Акъяр чишмәсе” биләмәсен төзекләндерүгә һәм тәртиптә тотуга**

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Карар кабул ителгәннән соң , 5 көннән дә соңга калмыйча, “Яңа Чишмә” район газетасында бастырырга.
4. Карар “Яңа Чишмә” район газетасы битләрендә бастырылган көннән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә йөклим.

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Акъяр авыл**
**җирлеге башлыгы: Д.С.Гайнуллин**